**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Мордва Афонькәсе авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге составына керүче Чуаш Афонькәсе авылы
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**12 октябрь 2023 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 12 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Чуаш Афонькәсе авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

1. Чуаш Афонькәсе авылы торак пунктында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

2. Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

3. Чуаш Афонькәсе авылындагы чишмәне төзекләндерү (вывесканы яңарту, буяу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 36 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 19 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 19 катнашучысы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенының 0 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Чуаш Афонькәсе авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2024 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Чуаш Афонькәсе авылы торак пунктында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Чуаш Афонькәсе авылындагы чишмәне төзекләндерү (вывесканы яңарту, буяу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 17 нче йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы А.И.Митяев